ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯМАШИРМӘАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422735, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Ямаширмә авылы, Совет ур,5 йорт

СОВЕТ ЯМАШУРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422735, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Ямашурма, ул.Советская, д. 5

Тел./факс: +7(84365) 777-02, e-mail: Yamash.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**29 ноябрь 2018 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№104**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында**

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”, 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, “Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы”, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмәавыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмәавыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында Нигезләмәне расларга.

2. Үз көчен югалткан дип таныргa:

Ямаширмә авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмәавыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партияләрдән кала) катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында”, 2017 елның 19 октябрендәге 64 номерлы карарын.

3. Әлеге Карарны Ямаширмә авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Биектау муниципаль районы сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җирлек башлыгы Ф.К.Мухтаров

Кушымта

Расланган
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Ямаширмәавыл җирлеге Советы
карары белән 29.11.2018 № 104

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмәавыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында

# НИГЕЗЛӘМӘ

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү турында әлеге Тәртип "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында", 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы 1 бүлеге 3 пунктны, "Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы", 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясы 1 бүлеге 3 пунктын тормышка ашыру максатыннан эшләп чыгарылган һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр) эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт алу процедурасын билгели.

2. Муниципаль хезмәткәр эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә түбәндәге коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга хокуклы: иҗтимагый оешмалар (сәяси партиялардән кала), торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары, күчемсез милек хуҗалары ширкәте – бердәнбер башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә (алга таба – коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катншау), әгәр дә бу мәнфәгатьләр конфликтын китереп чыгармаса, федераль законнарда күздә тотылган очраклардан кала.

Әлеге Тәртип максатларында "Коррупциягә каршы тору турында", 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы 1 бүлеге белән билгеләнелгән "мәнфәгатьләр каршылыгы" дигән төшенчә кулланыла.

3. Муниципаль хезмәткәр идарә органнары, попечительлек органнары яки күзәтчелек советларына, хөкүмәтнеке булмаган коммерциячел булмаган башка чит ил оешмаларына һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләүче аларның

структур бүлекчәләре составына керергә хокуклы түгел, әгәр дә башкасы Россия Федерациясе халыкара килешүләре яки Россия Федерациясе законнары тарафыннан күздә тотылмаса.

4. Муниципаль хезмәткәрнең коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашуы бары тик Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмәавыл җирлегендә муниципаль хезмәт узудан буш булган вакытта гына мөмкин.

5. Коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүгә рөхсәт алуга гариза муниципаль хезмәткәр тарафыннан эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә – Ямаширмәавыл җирлеге башлыгына язмача формада, әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча коммерциячел булмаган оешма белән идарә итү буенча эшчәнлекне тормышка ашыра башлаганчы 15 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

6. Гаризада түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, ул били торган муниципаль хезмәт вазыйфасы;

бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә планлаштырыла торган оешманың тулы исеме, аның юридик һәм факттагы адресы;

бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашу яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керүнең башлану һәм тәмамлану датасы, формасы һәм нигезе;

муниципаль хезмәткәр хәбәр итәргә кирәк дип тапкан башка мәгълүмат.

Гаризага коммерциячел булмаган оешманың учредитель документлары беркетелә.

7. Гариза түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партияләрдән кала) яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керүгә (Нигезләмәгә 2 нче кушымта) рөхсәт турында гаризаларны теркәү Журналында теркәлә һәм барлык беркетелгән документлар белән бергә Ямаширмәавыл җирлеге башлыгына өйрәнү һәм кергән гариза турында хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәттә үз-үзен тотышы буенча таләпләрне тоту һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиягә (алга таба – комиссия) җибәрү өчен тапшырыла.

8. Хәбәрнамә авыл җирлеге башлыгы тарафыннан кергән датадан өч көн дәвамында Комиссиягә тапшырыла.

9. Комиссия, Комиссия эш тәртибен регламентлаучы муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә, гаризаны карый.

10. Гаризаны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуда мәнфәгатьләр каршылыгы юк һәм идарә итүдә катнашу мөмкин һәм җирле үзидарә органыныда муниципаль хезмәт мәнфәгатьләренә каршы килми дип танырга;

б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуда мәнфәгатьләр

каршылыгын китереп чыгара яки китереп чыгарырга мөмкин һәм җирле үзидарә органынида муниципаль хезмәт мәнфәгатьләренә каршы килә һәм коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашу мөмкин түгел дип танырга.

Комиссия утырышы беркетмәсе күчермәсе утырыш көненнән 7 көн дәвамында эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә – авыл җирлеге башлыгына җибәрелә.

11. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмәавыл җирлеге башлыгы комиссия рекомендацияләрен исәпкә алып, әлеге Нигезләмәгә 3 нче Кушымтадагы форма нигезендә муниципаль хезмәткәргә түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт бирү турында әлеге Нигезләмәгә 3 нче Кушымтадагы форма нигезендә яки муниципаль хезмзткәр түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына кергән вакытта мәнфәгатьләр конфликты килеп туу мөмкинлеге булган очракта әлеге рөхсзтне бирүдән баш тарту турында, әлеге Нигезләмәгә 4 нче Кушымтадагы форма нигезендә дәлилләнгән карар кабул итә.

Күрсәтелгән карарның күчермәсе муниципаль хезмәткәргә кул куйдырып тапшырыла һәм муниципаль хезмзткәрнең шәхси эшенә беркетелә.

12. Муниципаль хезмәткәр коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүнең барлык чорында мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар күрергә, шулай ук эшкә алучы (эш бирүче) вәкилен мәнфәгатьләр конфликты яки аның килеп чыгу мөмкинлеге турында хәбәр бирергә тиеш.

13. Мәнфәгатьләр конфликтының ягы булган муниципаль хезмәткәр тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чараларны кабул итмәү муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмәавыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында Нигезләмәгә

___________________________________________

(эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең

___________________________________________

вазыйфасы һәм фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

___________________________________________

___________________________________________

(муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме,

___________________________________________

әтисенең исеме, вазыйфасы)

Коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуга рөхсәт алуга гариза

Миңа,

______________________________________________________________________

(муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазыйфасы)

түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга рөхсәт итүегезне сорыйм.

______________________________________________________________________

(коммерциячел булмаган оешманың тулы исеме, аның юридик һәм факттагы адресы, коммерциячел булмаган оешманың эшчәнлек өлкәсе)

______________________________________________________________________

(бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашу яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керүнең башлану һәм тәмамлану датасы, формасы һәм нигезе)

______________________________________________________________________

(муниципаль хезмәткәрнең коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу характеры (бердәнбер яки башкарма органы составында), оешмада вазыйфаның исеме, төп вазыйфаи йөкләмәләр, эш характерын тасвирлау (даими яки сроклы)

Гаризага беркетәм:

______________________________________________________________________

(коммерциячел булмаган оешманың учредитель документлары)

Дата___________________

Имза_________________

Элемтә өчен телефон________________

Гариза теркәү журналында теркәлгән

____________________20 __ел №_________________

(җаваплы затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмәавыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында Нигезләмәгә

## Түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партиядән кала) яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт бирү турында гаризаларны теркәү Журналы

| № т/б | Гариза биргән муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Гариза биргән муниципаль хезмәткәрнең вазыйфасы | Кадрлар хезмәтенә (кадрлар хезмәте бүлекчәсе, кадрлар эше буенча белгеч) гариза керү датасы | Гаризаны кабул иткән муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Гаризаны кабул иткән муниципаль хезмәткәрнең имзасы | Гаризаның күчермәсен алу турында муниципаль хезмәткәрнең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

3 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмәавыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында Нигезләмәгә

Коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуга
рөхсәт

_______________________________________________________________________________
_____
_______________________________________________________________________________
_____ (муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазыйфасы)

коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга рөхсәт ителә
_______________________________________________________________________________
____
_______________________________________________________________________________
_____
(коммерциячел булмаган оешманың исеме, юридик һәм факттагы адресы, ИННы, эшчәнлек өлкәсе)

_______________________________________________________________________________
_____ (муниципаль хезмәткәрнең коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу характеры (бердәнбер яки башкарма органы составында), оешмада вазыйфаның исеме, төп вазыйфаи йөкләмәләр, эш характерын тасвирлау (даими яки сроклы)

Дата____________________

Эшкә алучы вәкиле имзасы _______________

4 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмәавыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында Нигезләмәгә

## Коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуга рөхсәт бирүдән баш тарту

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазыйфасы)

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

______________ белән бәйле рәвештә

(баш тарту өчен нигезләр, хезмәттә үз-үзеңне тотуга таләпләрне тоту буенча Комиссия карарына сылтамалар)

коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу кире кагылды

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(коммерциячел булмаган оешманың исеме, юридик һәм факттагы адресы, ИННы, эшчәнлек өлкәсе)

________________________________________________________________________

Дата___________________

Эшкә алучы вәкиле имзасы _______________